**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Спас авыл җирлеге составына керүче Ефановка авылы торак пунктында гражданнар җыены карары**

**2023 елның 30 ноябре,** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Спас авыл җирлегенең Ефановка авылы торак пунктында гражданнар җыены

Карар кабул итте:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Спас авыл җирлегенең Ефановка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 сум күләмендә гражданнарның үзара салым салуын кертергә.
2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү:

- Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Ефановка авылындагы зиратта контейнер мәйданчыгы урнаштыру.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче**
**Спас авыл җирлеге башлыгы** **А. С. Мухалев**